ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының
**"Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышу турындагы ачык тыңлауларның**
**13 номерлы беркетмәсе**

**Рәсмиләштерү датасы:** 18.09.2026

**Рәсмиләштерү урыны:** 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча ш., Совет мәйданы, 27 йорт

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 21 августындагы 01-09-20098 номерлы хаты нигезендә оештырылды, Арча муниципаль районы Башлыгының "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны билгеләү турында" 2026 елның 26 августындагы 197 номерлы карары белән билгеләнде, түбәндәге урыннарда бастырылган:

- 2026 елның 26 августында Арча муниципаль районының рәсми сайтында: (https://arsk.tatarstan.ru);
- 2026 елның 26 августында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru).

Ачык тыңлауларны оештыручылар:
1) Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - И.А.Галимуллин;
2) Юридик мәсьәләләр бүлеге җитәкче - Л.Г.Сәгыйтова;
3) Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе — И.М.Хәсәнов;
4) Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" Башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Р.Багаутдинов;
5) Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе — И.Г.Сираҗиев.

Ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр 2026 елныд 26 августында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) басылып чыкты һәм анда **түбәндәге мәгълүматлар бар иде:**

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:
- Территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә (1 Том);
- Җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы (2 Том);
- Торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелеп килүче торак пунктлар чикләре) картасы (2 Том);
- Функциональ зоналар картасы (2 Том);
- Генераль планны нигезләү буенча материаллар. Әйләнә-тирә мохитне саклау. Аңлатма язуы (3 Том);
- Җирлек территориясеннән заманча файдалану картасы (4 Том);
- Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (гамәлдәге нигезләмә) (4 Том);
- Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (проект тәкъдиме) (4 Том);
- Инженерлык инфраструктурасы картасы (4 Том);
- Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр, Гражданнар оборонасы чаралары картасы (4 Том).
- Ачык тыңлауларны үткәрү тәртибе һәм сроклары;
- Ачык тыңлауларда катнашучылар даирәсе)
- Ачык тыңлаулар уздырыла торган Территория;
- Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы;
- Проект экспозициясен (экспозицияләрен) үткәрү сроклары;
- Экспозицияне (экспозицияләрне)карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;
- Ачык тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм формасы;
- Ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын (җыелышларын) үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат;
- Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат һәм аңа мәгълүмати материаллар;

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә уздырылды.

Ачык тыңлауларда катнашучыларның тәкъдимнәре һәм кисәтүләре 2026 елның 3 сентябреннән 2026 елның 18 сентябренә кадәр кабул ителде.

Күрсәтелгән чорда ачык тыңлауларда катнашучылардан тәкъдимнәр һәм кисәтүләр килмәде.

Ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне бастырып чыгару турындагы акт, проектны карауда катнашкан ачык тыңлауларда катнашучылар исемлеге кушымтада бирелә.

Имзалар:

Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
беренче урынбасары ________________ И.А.Галимуллин

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының инфраструктура
үсеше бүлеге җитәкчесе ________________ И.М.Хәсәнов

Арча муниципаль район Советының
юридик мәсьәләләр бүлеге җитәкчесе ________________ Л.Г.Сәгыйтова

Арча муниципаль районының
“Арча шәһәре” Башкарма комитеты
җитәкчесе ________________ Р.Р.Багаутдинов

Арча муниципаль районының
Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре
палатасы җитәкчесе ________________ И.Г.Сираҗиев